СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.08.2018 с. Верхний Услон № 36-406

**2018нче елда өлкән яшьтәге кешеләр өчен диспансеризация буенча чараларны тормышка ашыру турында**

"Югары Ослан үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы А.О.Смирновның 2018нче елда өлкән яшьтәге кешеләр өчен диспансеризация буенча чараларны тормышка ашыру турында белдерүен тыңлап һәм фикер алышып,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар кылды:**

1. 2018нче елда өлкән яшьтәге кешеләр өчен диспансеризация буенча чараларны тормышка ашыру турында белдерүен исәпкә алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына төрле ведомстволар, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълумат чараларының иҗтимагый партнёрлык һәм хезмәттәшлек нигезендә өлкән яшьтәге кешеләр өчен диспансеризация чараларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча эшне дәвам итергә.

3.Тәкъдим итергә:

3.1. "Югары Ослан үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә:

- өлкән яшьтәге кешеләр өчен диспансеризация тәртибен гамәлдәге канун таләпләре белән туры китереп үтәргә;
- өлкән яшьтәге кешеләр өчен диспансеризация чараларын тормышка ашыру максатында профилактик юнәлеш буенча эшне көчәйтергә;
- диспансеризация узу мәсьәләләре буенча, диспансеризация узуның кирәклеге һәм мөһим булуы турында халыкка хәбәр җиткерү буенча эшне активлаштырырга;

3.2. Югары Ослан муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә, оештыру-хокук формалары һәм милек

формаларына кармастан, эшчеләрнең тоткарлыксыз диспансеризация узуын тәэмин итүдә булышлык итергә, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда мобиль медицина бригадалары эшләү өчен кирәкле шартларны булдыруга булышлык итергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының иҗтимагый–мәдәният һәм яшьләр эшләре комиссияләренә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы Башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**